ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабрь 2019 ел № 6495

Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы карары белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 нче карары белән (Башкарма комитетның 2019 елның 16 маендагы 2519 номерлы карары редакциясендә) расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 1) бюджет акчалары белән баш эш итүчеләр (эш итүчеләр, алучылар), шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);»;

2) 9 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) түбәндәгеләр булып торган юридик затлар (муниципаль учреждениеләрдән, муниципаль унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) булган коммерцияле оешмалардан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар:

шәһәр бюджетыннан акчалар бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) һәм (яки) муниципаль контрактлар нигезендә шәһәр бюджетыннан акчалар, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

федераль законнар нигезендә Федераль казначылыкта шәхси счетлары ачылган һәм шәһәр бюджетыннан акчалар бирү турындагы шартнамәләрне (килешүләрне) һәм (яки) муниципаль контрактларны үтәү максатында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча үтәүчеләр (тәэмин итүчеләр, подрядчылар);»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 9.1 – 9.2. пунктларны өстәргә:

«9.1. Шәһәр бюджетыннан акчалар бирү турында шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү, шулай ук күрсәтелгән шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатында төзелгән контрактлар (шартнамәләр, килешүләр) һәм муниципаль контрактлар шартларын үтәү, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, күрсәтелгән юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчаларын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү өлешендә, контроль объектларына карата (бюджет процессында катнашучылардан, бюджет һәм автономияле учреждениеләрдән, муниципаль унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) булган коммерцияле оешмалардан тыш) муниципаль финанс контроле бюджет акчалары белән баш эш итүчеләрне (эш итүчеләрне), бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларын, бюджеттан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр), муниципаль контрактлар төзегән бюджет акчаларын алучыларны тикшерү процессында яки ул тәмамланганнан соң күрсәтелгән бюджет процессында катнашучыларны тикшерүне үткәрү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

9.2. Финанс идарәсенең эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре булып түбәндәгеләр тора:

1) бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган, шул исәптән бухгалтерык хисабына һәм муниципаль учреждениеләрнең бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзүгә һәм тапшыруга таләпләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләре үтәлешенә контроль:

2) ачык норматив йөкләмәләрнең һәм шәһәр бюджетыннан физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләрнең шартларын билгели торган хокукый актлар нигезләмәләре үтәлешенә, шулай ук шәһәр бюджетыннан акчалар бирү турында шартнамәләрнең (килешүләрнең), муниципаль контрактларның шартлары үтәлешенә контроль;

3) бюджеттан акчалар бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартлары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда, муниципаль контрактларны үтәү максатында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартлары үтәлешенә контроль;

4) бюджет акчаларын (бюджеттан бирелгән акчаларны) бирү һәм (яки) файдалану нәтиҗәләре турындагы хисапларның, шул исәптән муниципаль программаларны тормышка ашыру турындагы хисапларның, муниципаль йөкләмәләрнең үтәлеше турындагы хисапларның, бюджеттан акчалар бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапларның дөреслегенә контроль.»;

4) 10 пунктта:

- түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчаны өстәргә:

«2.1) тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр үткәрү өчен кирәкле экспертизалар уздыруны билгелиләр (оештыралар);»;

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына, финанс идарәсе башлыгына мәҗбүри бюджет чаралары куллану турында белдерү кәгазе җибәрәләр;»;

- түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) Россия Федерациясенең мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турындагы законнары, Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы законнары нигезендә, эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларына даими керә алу мөмкинлеген алалар.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин